**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиллеге эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Указына һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләргә социаль гарантияләрне тәэмин итү, аларның хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу максатында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиллеге эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 25 августындагы ПУ-320 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта «, компенсация түләүләрен исәпкә алып» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктта:

«а» пунктчасында «50» санын «сигез» сүзенә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, айлык ике тариф ставкасы» сүзләрен «айлык бер тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында:

икенче абзацта «25» санын «биш» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «10 процент» сүзләрен «ике процент» сүзләренә алмаштырырга;

«д» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

в) 4 пунктта:

өченче абзацта «35» санын «җиде» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» санын «10» санына алмаштырырга;

г) 5 пунктта:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «айлык алты тариф ставкасы» сүзләрен «айлык бер тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «айлык өч тариф ставкасы» сүзләрен «айлык бер тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, айлык ике тариф ставкасы» сүзләрен «айлык бер тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «айлык алты тариф ставкасы» сүзләрен «айлык 1,5 тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «айлык бер тариф ставкасы» сүзләрен «айлык 0,3 тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта:

өченче абзацта «компенсация түләүләре,» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 пунктта:

1 пунктчада «50» санын «сигез» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, айлык ике тариф ставкасы» сүзләрен «айлык бер тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада:

икенче абзацта «25» санын «биш» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «10 процент» сүзләрен «ике процент» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктчада:

өченче абзацта «35» санын «җиде» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» санын «10» санына алмаштырырга;

в) 7 пунктта:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчада «айлык тугыз тариф ставкасы» сүзләрен «айлык 1,8 тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык өч тариф ставкасы» сүзләрен «айлык бер тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, айлык ике тариф ставкасы» сүзләрен «айлык бер тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарын карап тотуга бүлеп бирелә торган акчалар чикләрендә ел саен Татарстан Республикасы бюджетында әлеге Указда каралган үзгәрешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы тиешле дәүләт органнарының эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү буенча чыгымнарны финанслауны тәэмин итүгә акчалар карауны;

үз норматив хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә Татарстан Республикасы тиешле дәүләт органнарының эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләргә өстәмәләр һәм башка өстәмә түләүләр билгеләү турында элек чыгарылган актларын әлеге Указга туры китерергә.

5. Әлеге Указ, әлеге Указның 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк 1 һәм 2 пунктларыннан кала, аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 13 декабрь
№ ПУ-944